**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**17.04.2018** **№ 871**

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
муниципаль учреждениеләре
һәм муниципаль оешмалары
хезмәткәрләренең хезмәт
хакын арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2014 елның 18 октябрендәге 768 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 15 декабрендәге 1000 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында» 2010 елныж 24 августындагы 1643 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан вазыйфаи окладка, стимуллаштыру характерындагы түләүләргә (башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр һәм премиаль түләүләрдән тыш) һәм авыл җирендә эшләгән өчен түләүләргә 14 процент күләмендә өстәмә өстәүләр билгеләргә, аларга хезмәт өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары белән җайга салына:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы;

«Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 елның 10 декабрендәге 1072 номерлы.

2. Әлеге карар үз гамәлен 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Д.Ф. Шәйдуллин